**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**13.12.2021** № **04-05-138**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 23 нче мартында чыккан 04-14-41 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 18 нче ноябрендә чыккан "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы иҗтимагый совет турында" 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 23 нче мартында чыккан 04-14-41 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 нче елның 12 нче маенда чыккан 04-14-64 номерлы, 2017 нче елның 9 нчы ноябрендә чыккан 04-14-162 номерлы, 2019 нчы елның 3 нче июнендә чыккан 04-05-59 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"Дәүләт комитеты эшчәнлеге артыннан җәмәгать контролен гамәлгә ашыру";

2.2 нче пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

"2.2. Иҗтимагый советның бурычлары:

сатып алулар өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

Дәүләт комитеты тарафыннан карарлар кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Дәүләт комитетының төп эшчәнлеге буенча халыкның хәбәрдарлык дәрәҗәсен арттыру;

җәмгыятьтә ришвәтчелеккә бәйле хәлләргә карата тискәре караш формалаштыру”;

2 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 2.4 нче пункт белән тулыландырырга:

“2.4. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

сатып алулар өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

ришвәтчелеккә каршы көрәш чараларында катнаша;

2014 нче елның 21 нче июлендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында” 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Иҗтимагый совет утырышында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмаган Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра;

Дәүләт комитетының дәүләт сатып алуларының нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазифасын биләүгә конкурс үткәрү буенча конкурс комиссияләре һәм дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүче дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә аттестация үткәрү буенча аттестация комиссияләре эшендә катнаша”;

3.6 нчы пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“әлеге Нигезләмәнең 6.6 нчы пунктында каралган сәбәпләрнең булуы”;

3.7 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү”;

3.8 нче пунктында:

беренче абзацта “яисә рәис урынбасары” сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта “яисә рәис урынбасарына” сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 нчы бүлек белән тулыландырырга:

“6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр каршылыгы

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы – Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынучанлыгы аның үз бурычларын тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә (вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга) йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган һәм Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынучанлыгы белән Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның объективлыгына һәм гаделлегенә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынучанлыгы астында Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, яисә үзе яки өченче затлар өчен хезмәт рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы язма рәвештә Иҗтимагый совет рәисенә һәм Дәүләт комитеты рәисенә барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгы турында яисә аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аңа билгеле булгач та, ә Иҗтимагый совет рәисе язмача бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына хәбәр итәргә бурычлы.

Иҗтимагый совет рәисе язма рәвештә Дәүләт комитеты рәисенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгы турында яисә аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аңа билгеле булгач та, хәбәр итәргә бурычлы.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрдар булган Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча, шул исәптән мәнфәгатьләр каршылыгы тарафы булган Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору яисә туктату турында Дәүләт комитеты рәисенә тәкъдим кертү юлы белән, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы билгеләгән тәртиптә чаралар күрергә тиеш.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет эшчәнлегендәге ришвәтчелек куркынычын бәяли һәм Иҗтимагый совет әгъзаларының ришвәтчелеккә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашуына юл куймау максатларында аларны минимальләштерү буенча чаралар күрә.

Иҗтимагый совет әгъзасының ришвәтчелеккә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты турында хәбәрдар булган Иҗтимагый совет рәисе бу хакта өч эш көне эчендә Дәүләт комитеты рәисенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең ришвәтчелеккә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты турында хәбәрдар булган Иҗтимагый совет әгъзалары бу хакта өч эш көне эчендә Дәүләт комитеты рәисенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

6.6. Иҗтимагый совет әгъзасының ришвәтчелеккә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүмат алу очракларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Дәүләт комитеты рәисенә бу әгъзаның Иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында тәкъдим кертә.

Дәүләт комитеты рәисенең Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору турындагы карары Дәүләт комитеты боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка китерә торган шартлар бетерелмәсә, яисә Иҗтимагый совет рәисенең ришвәтчелеккә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланса, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы

Дәүләт комитеты рәисенә Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Дәүләт комитеты рәисенең Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату турындагы карары Дәүләт комитеты боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка китерә торган шартлар бетерелгән (расланмаган), һәм (яисә) Иҗтимагый совет әгъзасының ришвәтчелеккә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Дәүләт комитеты рәисенә Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен кайтару турында тәкъдим кертә.

Дәүләт комитеты рәисенең Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен кайтару турындагы карары Дәүләт комитеты боерыгы белән расланырга тиеш”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары М.С. Ротарьга йөкләргә.

Рәис Р.Н. Сабиров